Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы
Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башкарма комитеты

КАРАР

31 октябрь, 2022 ел

№ 13

«Белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башкарма комитеты 2022 елның 17 мартындагы 4 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрне электрон рәвештә күрсәтүгә таләпләр турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 26 мартындагы 236 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

1. «Белешмә (выписка) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге Башкарма комитетының 2022 елның 17 мартындагы 4 номерлы карары белән расланган белешмә (өземтә) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.3.2.1 пунктындагы 11 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Формалаштырылган гаризаны формат-логик тикшерү мөрәҗәгать итүче тарафыннан гаризаның электрон формасы кырларының һәркайсын тутыру процессында автомат рәвештә бердәм портал тарафыннан гамәлгә ашырыла. Бердәм портал тарафыннан дөрес тутырылмаган электрон рәвештәге гариза бирүче ачыкланган хатаның характеры һәм аны мәгълүмати хәбәр итү юлы белән турыдан-туры гаризаның электрон формасында бетерү тәртибе турында хәбәр итә.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматы рәсми порталында (www.pravo.tatarstan.ru) һәм Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Керәшен Сәрдәсе авыл җирлеге башлыгы Н.В. Морозов